СОВЕТ СОБОЛЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.7, с. Шеланга,
422577

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
СОБОЛЕВСКИЙАВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Совет ур., 7 нче йорт, Шланга авылы,
422577

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ КАРАР

19.09.2024 с.Соболевское № 46-234

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 13 ноябрендәге 269 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 13 ноябрендәге 269 номерлы Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Түбәндәге күләмдә салым ставкаларын билгеләргә:

1) түбәндәгеләргә карата 0,1 процент:

гараж һәм машина - урын;

һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык яисә индивидуаль торак төзелеше өчен җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмалары яисә корылмалар;

2) түбәндәгеләргә карата 0,2 процент:

- фатирлар, фатирлар өлешләре;

- бүлмәләр, бүлмәләр өлешләре;

3) түбәндәгеләргә карата 0,3 процент :

- торак йортлар, торак йортлар өлешләре;

- мондый объектларны проектлаштыручы билгеләнеше торак йорт булса, тәгәлләнмәгән төзелеш объектлары;

составына бер генә торак йорт керә торган бердәм күчемсез комплекслар;

4) салым салуның башка объектларына карата 0,5 процент;

5) 2025-2027 еллар чорына 1,2 процент, 2028 елда һәм аннан соңгы

елларда административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) карата гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артык булган һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә торган исемлеккә кертелгән биналарга карата Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясы нигезендә - 2 процент .

6) 2 процент - Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына карата; Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата;

7) һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата - 2025 елда -2 процент, 2026 елда һәм аннан соңгы елларда-2,5 процент»;

2. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында» карар текстын яңа редакциядә расларга (1 нче кушымта).

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Совет рәисе,
ТР Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге башлыгы О.Н.Майорова

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге Советының
2024 елның 19 сентябрендәге
46-234 номерлы карарына

1 кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә мәҗбүри түләү салымын билгеләргә һәм гамәлгә кертергә

2. Түбәндәге күләмдә салым ставкаларын билгеләргә:

1) түбәндәгеләргә карата 0,1 процент:

- гараж һәм машина урыны;

һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык яисә индивидуаль торак төзелеше өчен җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмалары яисә корылмалар;

2) түбәндәгеләргә карата 0,2 процент:

- фатирлар, фатирлар өлешләре;

- бүлмәләр, бүлмәләр өлешләре;

3) түбәндәгеләргә карата 0,3 процент :

- торак йортлар, торак йортлар өлешләре;

- мондый объектларны проектлаштыручы билгеләнеше торак йорт булса, тәгәлләнмәгән төзелеш объектлары;

составына бер генә торак йорт керә торган бердәм күчемсез комплекслар;

4) салым салуның башка объектларына карата 0,5 процент;

5) 2025-2027еллар чорына - 1,2 процент, 2028 елда һәм аннан соңгы елларда административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) карата гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артык булган һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә торган исемлеккә кертелгән биналарга карата Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясы нигезендә - 2 процент.

6) Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына; Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата - 2 процент;

7) һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата - 2025 елда - 2 процент, 2026 елда һәм аннан соңгы елларда-2,5 процент»;

3. Ике фатирдан торган күпфатирлы бер катлы торак йортта фатир милекчеләренә исәпләнгән салым суммасын әлеге фатирның гомуми мәйданының утыз квадрат метрының кадастр бәясендә салым ставкасының процент өлеше буларак билгеләнә торган суммага киметү рәвешендә ташлама билгеләргә.

Әгәр фатир гомуми өлешле милектә булса, ташламаларның суммасы өлешле милектә катнашучыларның һәркайсы өчен әлеге фатирга милек хокукында пропорциональ рәвештә исәпләнә.

Әгәр фатир уртак милектә булса, ташламалар суммасы уртак милектә

катнашучыларның һәркайсы өчен тигез өлешләрдә исәпләнә.

Бу очракта әлеге пункт нигезендә исәпләнгән ташламалар суммасы аны исәпкә алмыйча исәпләнгән салым суммасыннан артып китә алмый.

Совет Рәисе
ТР Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге башлыгы О.Н.Майорова